| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2020 Азево авылы № 57-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 39-1 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 39-1 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент аста санап үтелгәннәргә карата:

салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар, шул исәптән әлеге пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

2) 0,2 процент аста санап үтелгәннәргә карата

фатир, фатирларның бер өлеше, бүлмәләр;

3) 0,3 процент аста санап үтелгәннәргә карата:

торак йортларның, торак йортларның өлешләренең;

әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент аста санап үтелгәннәргә карата:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына, шулай ук һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата.

5) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.».

1.2. 2.1., 2.2. пунктчаларны 2.1., 2.2. пунктлары дип санарга.

1.3. 2.2. пунктының 5) пунктчасында «бирелгән», «дача» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. 2.2. пунктының 9,10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында белдерү салым түләүченең салым органына үз теләге белән әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булып торучы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.».

1.5. Карарны түбәндәге эчтәлекле 2.3. пункты белән тулыландырырга:

«2.3. Салым салу объектларына карата салым базасы (фатир, фатир өлеше, бүлмә, торак йорт, торак йорт өлеше), өч һәм аннан күбрәк балалары булган физик затлар милкендә булган, фатирның, фатирның бер өлешенең, бүлмәнең, фатирның гомуми мәйданының 5 квадрат метры булган кадастр бәясе зурлыгына, һәм торак йортның гомуми мәйданының 7 квадрат метрына, һәр балигъ булмаган балага исәплләгәндә торак йортның бер өлешенә киметелә.

Әлеге пунктта каралган салым тотып калынган акча һәр салым салу объектының (фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә, торак йорт, торак йортнын) бер өлешенә карата Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 6 һәм 7 пунктларында каралган тәртиптә, шул исәптән салым органына тиешле гариза, хәбәрнамә тапшырмаган очракта бирелә.».

2. Әлеге карарның 1.5 пункты 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча), һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет, социаль Законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе В.С. Семенов